ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2019 №_916

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 1430 нчы санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында»гы 2014 елның 9 июлендәге 765 нче санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 1430 нчы санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1. Карар исемендәге «2016-2020 елларга» сүзләрен «2016-2021 елларга» сүзләренә алмаштырырга.

2. «2016-2021 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын яңа редакциядә расларга.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э. И. Садыйкова) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. әлеге максатларга җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр кысаларында программаны финанслауны гамәлгә ашыруны;

3.2. чираттагы финанс елына Алабуга муниципаль районы бюджетын формалаштырганда муниципаль программа чараларын финанслау күләмен җыелма бюджет язмасына кертергә.

4. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин